**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**РУКОВОДИТЕЛЬ**
**Исполнительного комитета**
**Азнакаевского**
**муниципального района**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы**
**башкарма комитеты**
**ҖИТӘКЧЕСЕ**

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

« 14 » 05 2018 ел № 101

Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының 2014 елның 20 мартындагы 39 нчы номерлы «Азнакай муниципаль районының муниципаль бюджет мәгариф учреждениеләре җитәкчеләренең эшчәнлеген бәяләү критерийлары турында» карарына үзгәрешләр кертү турында (2015 елның 20 октябрендәге 283 номерлы, 2017 елның 10 ноябрендәге 287 номерлы, 2018 елның мартындагы 66 номерлы карарлар редакциясендә)

Азнакай муниципаль районының муниципаль бюджет мәгариф учреждениеләре җитәкчеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру максатларында карар бирәм:

1. Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының 2014 елның 20 мартындагы 39 нчы номерлы «Азнакай муниципаль районының муниципаль бюджет мәгариф учреждениеләре җитәкчеләренең эшчәнлеген бәяләү критерийлары турында» карарына (2015 елның 20 октябрендәге 283 номерлы, 2017 елның 10 ноябрендәге 287 номерлы, 2018 елның мартындагы 66 номерлы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 18 августындагы 592 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре һәм дәүләт медицина һәм мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләүнең яңа системаларын кертү турында», «Азнакай муниципаль районының муниципаль бюджет мәгариф учреждениеләре җитәкчеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру максатларында Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2010 елның 24 августындагы 678 номерлы карарлары нигезендә карар бирәм:»;

1.2. 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе җитәкчесен стимуллаштыруга хезмәт өчен түләү фонды өлеше учреждение хезмәте өчен түләүнең гомуми фондыннан 1 процентка тигез дип билгеләргә. Стимуллаштыру характерындагы түләүләр күләме муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе эшчәнлеге нәтиҗәләрен исәпкә алып билгеләнә һәм муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе җитәкчесен стимуллаштыру фондының 50 процентын тәшкил итә. "

2. 2-5 пунктларын 3-6 пунктлар дип санарга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2014 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны веб-адрес буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru//.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад һәм финанс буенча урынбасары Г.Г. Сөләймановага йөкләргә.

Җитәкче А.Х.Шәмсетдинов